**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**«КАЛМАШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ» МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ СОВЕТЫ**

«01» октябрь 2024 ел № 18/1

# КАРАР

«Физик затлар мөлкәтенә салым турында» Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы «Калмаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2016 елның 26 сентябрендәге 8/6 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Салым кодексының 32 бүлеге, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы «Калмаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставы нигезендә Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Калмаш авыл җирлеге Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы «Калмаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2016 елның 26 сентябрендәге 8/6 номерлы карарына (01.11.2023 № 13/1 карарлар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. карарның 2 пункты 6 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6) Россия Федерациясе Салым кодексының 378.2 статьясы 7 пункты нигезендә билгеләнгән исемлеккә кертелгән, гомуми мәйданы 1000 квадрат метрдан 2000 квадрат метрга кадәр булган административ-эшлекле үзәкләргә һәм сәүдә үзәкләренә (комплексларына) һәм алардагы урыннарга карата һәм Россия Федерациясе Салым кодексының 378.2 статьясы 10 пункты икенче абзацында каралган салым салу объектларына карата 2025-2027 еллар күчеш чорына 1,2 процент.»

1.2. карарның 2 пункты 6 пунктчасын 7 пунктчасы дип санарга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының рәсми сайтында (tukay.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карар 2025 елның 1 гыйнвареннан, әмма рәсми басылып чыккан көненнән 1 айдан да иртәрәк булмаган вакытта үз көченә керә.

4. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны Калмаш авыл җирлеге Советының законлылык һәм хокук тәртибе буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Совет Рәисе,
ТР Тукай муниципаль районы
Калмаш авыл җирлеге Башлыгы Ф.В.Шәвәлиев

ОГРН 1021601372781
р.05-11797/09
Совет КАЛМАШСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ИНН 1639009753